Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Белкино авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Белкино авыл җирлеге Башлыгы
КАРАРЫ

19 октябрь, 2020 ел № 1

Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06.10.131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлеге уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Белкино авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 декабрендәге 127 номерлы Белкино авыл җирлеге Советы карары нигезендә карар бирәм:

1. Белкино авыл җирлегендә түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләргә:

1.1. Чертово авылында. 2020 елның 6 ноябрендә 10.00 сәгатьтә Икмәк урамындагы 4 нче йорт янында гражданнар җыенын үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез 2021 елда Чертово торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2. Белкино авылында. Гражданнар җыенын 2020 елның 6 ноябрендә 14 сәгать 14.00 сәгатьтә Мәктәп урамындагы авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез 2021 елда Белкино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Белкино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Белкино авыл җирлеге башлыгы А. Н. Меньшов